# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында умартачылыкны дәүләт тарафыннан җайга салу һәм аңа дәүләт ярдәме турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 2 ноябрендә
кабул ителде

Әлеге Закон бал кортларын карап тоту, алардан умартачылык продуктларын алу, авыл хуҗалыгының энтомофиль үсемлекләрен серкәләндерү өчен файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала, умарталарның физик, психологик тискәре йогынтысыннан кешеләрнең иминлеген тәэмин итүгә, Татарстан Республикасы территориясендә умартачылык белән шөгыльләнүче физик һәм юридик затларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүгә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә умартачылыкка дәүләт ярдәме күрсәтүгә юнәлдерелгән.

1 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

умартачылык – бал кортларын үрчетү һәм карап тоту, алардан умартачылык продуктларын алу, авыл хуҗалыгының энтомофиль үсемлекләрен серкәләндерү өчен файдалану;

умартачылык субъектлары – умартачылык белән шөгыльләнүче физик һәм юридик затлар;

умарта күче (пакет) – умарта оясында яисә куышта яшәүче эшче кортлардан, соры кортлардан һәм ана корттан торучы бал кортлары җыелмасы;

умарта оясы – умарта күчен карап тоту өчен корылма;

умарталык – умарта күчләре һәм умартачылык белән шөгыльләнү өчен кирәкле мөлкәт белән билгеле бер урында урнаштырылган умарта оялары;

стационар умарталык – ел дәвамында даими урында урнаштырылган умарталык;

күчмә умарталык – бал җыю чыганаклары яисә авыл хуҗалыгының энтомофиль үсемлекләре массивлары янында вакытлыча урнаштырылган умарталык;

умартачылык продуктлары – бал кортлары житештергән продуктлар (табигый бал, балавыз һәм башкалар), шулай ук бал кортлары үзләре;

бал кортлары токымы – билгеле бер климат шартларында табигый сайлану йогынтысында барлыкка килә һәм буыннан-буынга тотрыклы рәвештә күчеп килә торган билгеләр комплексына ия умарта күчләре төркеме;

бал кортларының популяциясе – бал кортлары токымы чикләрендә билгеле бер территориядә барлыкка килә торган һәм гомуми генофондка ия бал кортлары токымы чикләрендә умарта күчләре җыелмасы;

ана корт – бал кортларын тудыручы корт;

энтомофиль үсемлекләр – бөҗәкләр серкәләндерә торган үсемлекләр;

бал җыю чыганаклары – нектар һәм серкә барлыкка китерә торган, бал кортлары өчен табигый азык һәм бал җыю чыганагы булып торучы үсемлекләр;

табигый бал – нектарны яисә падьны (татлы куе сыекчаны) бал кортлары эшкәрткәннән соң барлыкка килгән продукт;

терлекчелек корылмалары – авыл хуҗалыгы хайваннарын үстерү һәм терлекчелек продукциясен (сөт, ит, йомырка, йон һ.б.ш.) җитештерү өчен билгеләнгән биналар.

2 статья. **Умартачылык өлкәсендә хокукый җайга салу**

Умартачылык өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Умартачылык өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру хокукы**

Татарстан Республикасы территориясендә умартачылык өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру хокукына физик һәм юридик затлар ия.

4 статья. **Умарта күчләре (пакетлары) саны**

Умартачылык субъектларының умарта күчләре (пакетлары) саны чикләнми.

5 статья. **Умартачылык өлкәсендә дәүләт ярдәме чаралары**

1. Умартачылык өлкәсендә дәүләт ярдәме, оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә, барлык умартачылык субъектларына кагыла һәм түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

1) умартачылыкны үстерү буенча максатчан программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) бал кортларының авыруларын кисәтү, аларны дәвалау, умарта күчләре корткычларына каршы көрәш һәм бал кортларын пестицидлар һәм агрохимикатлар белән агулауны булдырмау чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

3) умарталарның эпизоотиясен, карантинлы һәм аеруча куркыныч авыруларын бетерү, умартачылык өлкәсендә фәнни тикшеренүләр, шулай ук умарталарны һәм аларның яшәү тирәлеген саклау чараларын үткәрү чыгымнарына компенсацияләр бирү;

4) законнарда каралган тәртиптә салым ташламалары бирү;

5) ташламалы шартларда кредитлар бирү һәм инвестицияләр җәлеп итү;

6) умартачылыкны үстерүгә ярдәм итүгә субсидияләр бирү;

7) Татарстан Республикасы милкендәге урман кишәрлекләрен урман турындагы законнар нигезендә умартачылык белән шөгыльләнү өчен (шул исәптән күчмә умарталыкларны урнаштыру өчен) бирү һәм күрсәтелгән максатлардагы урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен ташламалы ставкалар, аренда түләве билгеләү;

8) икътисадый кызыксындыруның башка чараларын куллану.

2. Әлеге статьяда билгеләнгән дәүләт ярдәме чараларын (әлеге статьяның 1 өлешендәге 4 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән чаралардан тыш) гамәлгә ашыру шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Умартачылык өлкәсендә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасы бюджетында карала торган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Җирле үзидарә органнары җирле бюджетлар акчалары исәбеннән умартачылык субъектларына ярдәм итү өчен өстәмә чаралар билгеләргә хокуклы.

6 статья. **Умартачылык субъектларына дәүләт ярдәме принциплары һәм шартлары**

1. Татарстан Республикасында умартачылык субъектларына дәүләт ярдәменең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) умартачылык субъектларының, ярдәм итүне сорап, гариза белән мөрәҗәгать итү тәртибе;

2) умартачылыкны үстерүнең республика, муниципальара һәм муниципаль программаларында каралган критерийларга туры килә торган умартачылык субъектларының тиешле программаларда катнашуга бертигез дәрәҗәдә кертелүе;

3) законнарда билгеләнгән таләпләрне үтәгән килеш ярдәм күрсәтү;

4) ярдәм күрсәтү процедураларының ачык булуы.

2. Дәүләт ярдәме күрсәтүдән түбәндәге очракларда баш тартылырга тиеш, әгәр:

1) мөрәҗәгать итүче умартачылыкны үстерүнең республика, муниципальара һәм муниципаль программаларында билгеләнгән документларны тапшырмаса яисә ялган белешмәләр һәм документлар тапшырса;

2) дәүләт ярдәмен күрсәтү шартлары үтәлмәсә;

3) мөрәҗәгать итүчегә – умартачылык субъектына карата шундый ярдәм күрсәтү турында элегрәк карар кабул ителгән һәм аны күрсәтү сроклары үтмәгән булса;

4) мөрәҗәгать итүчене ярдәм итү тәртибен һәм шартларын бозган, шул исәптән ярдәм итү акчаларыннан максатчан файдалануны тәэмин итмәгән дип таныган вакыттан соң өч елдан кимрәк вакыт узган булса.

7 статья. **Стационар умарталыкларны урнаштыру**

1. Умартачылык субъектлары умарта күчләре (пакетлары) белән ояларны үзләре милкендәге, биләвендәге, файдалануындагы яисә арендасындагы җир кишәрлекләрендә законнар нигезендә урнаштыралар.

2. Умарталарның физик, психологик тискәре йогынтысыннан кешеләрнең иминлеген тәэмин итү максатларында умарта күчләре белән ояларны җир кишәрлегендә аның чигеннән ун метрдан да якынрак булмаган арада урнаштыралар йә башка җир кишәрлегеннән бина, корылма, тоташ койма яисә бал бирә торган агачлар һәм биеклеге ике метрдан да кимрәк булмаган куе куаклык белән аералар.

3. Стационар умарталыкларны терлекчелек корылмаларыннан кимендә бер километр ераклыкта, кондитерлык яисә химия сәнәгате предприятиеләреннән кимендә биш километр ераклыкта урнаштыралар.

8 статья. **Күчмә умарталыкларны урнаштыру өчен җир кишәрлекләре бирү**

1. Күчмә умарталыкларны урнаштыру өчен уңайлырак җир кишәрлекләренең милекчеләре, биләүчеләре, файдаланучылары, арендалаучылары аларны умартачылык субъектларына, умарта күчләрен теркәү урынына бәйсез рәвештә, Россия Федерациясе законнары нигезендә бирә алалар.

2. Күчмә умарталыклар стационар умарталыклардан кимендә дүрт километр ераклыкта урнаштырыла.

3. Моңа кадәр урнаштырылган башка умарталыктан умарталарның бал җыю урынына очу юлларында күчмә умарталыклар урнаштыру һәм аерылып чыккан илләрне тоту өчен җайланмалар кую рөхсәт ителми.

4. Умартачылык субъектлары күчмә умарталыкны урнаштырганнан соң җирле үзидарә органнарына аның турындагы белешмәләрне хәбәр итәргә һәм умарталыкның ветеринария-санитария паспортын күрсәтергә тиеш.

9 статья. **Авыл хуҗалыгының энтомофиль үсемлекләрен серкәләндерү өчен умарта күчләреннән файдалану**

Авыл хуҗалыгының энтомофиль үсемлекләрен үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнар һәм юридик затлар аларның уңдырышлылыгын арттыру максатларында башка затлар милкендәге умарта күчләреннән граждан законнары нигезендәге шартнамәләр буенча авыл хуҗалыгының энтомофиль үсемлекләрен серкәләндерү өчен файдалана алалар.

10 статья. **Умартачылык продуктларын реализацияләү**

1. Табигый бал һәм умартачылыкның башка продуктлары аларның хуҗалары тарафыннан законнар нигезендә реализацияләнә.

2. Табигый бал һәм умартачылыкның башка продуктлары сыйфат характеристикалары буенча кешеләр сәламәтлеге өчен билгеләнгән хәвефсезлек таләпләренә туры килергә тиеш.

3. Умартачылык субъектының дәүләт ветеринария учреждениесеннән тиешле язмалар белән ветеринария-санитария паспорты булырга тиеш, аның нигезендә умарталарны һәм умартачылык продуктларын ташуга, күчерүгә, сатуга рөхсәт бирелә. Умарталарны һәм умартачылык продуктларын ташу, күчерү, сату тиешле ветеринария документлары булганда гамәлгә ашырыла.

4. Табигый балны реализацияләүче физик һәм юридик затларда түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) реализация урынына (базар, ярминкә, күпләп реализацияләү һ.б.) бәйсез рәвештә, күрсәтелгән продукциягә ветеринария таләпләре нигезендә ветеринария-санитария экспертизасы бәяләмәсе;

2) муниципаль берәмлек чикләреннән тыш реализацияләгәндә дәүләт ветеринария учреждениесе тарафыннан бирелә торган ветеринария таныклыгы – йөртелә торган йөкнең һәм ул чыккан урынның ветеринария-санитария торышын тасвирлый торган йөртү документы.

11 статья. **Бал кортларын саклау**

Бал кортларын саклау түбәндәге юллар белән тәэмин ителә:

умартачылык субъектлары тарафыннан зоотехника һәм ветеринария-санитария нормаларын һәм бал кортларын карап тоту һәм умарта күчләре (пакетлары) белән умарта ояларын бал җыю чыганаклары янында урнаштыру кагыйдәләрен үтәү;

умартачылык субъектлары тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау кагыйдәләрен үтәү;

умарта күчләрен туздырудан һәм белә торып юкка чыгарудан яклау;

бал кортларын пестицидлар һәм агрохимикатлар белән агулауны булдырмау;

умарталар авыруларын профилактикалау һәм дәвалау буенча, умарта күчләре корткычларына каршы көрәш буенча ветеринария-санитария ярдәмен күрсәтү;

ветеринария кагыйдәләре нигезендә дезинфекция һәм дератизация буенча профилактик чаралар уздыру.

12 статья. **Бал кортларының генотипларын саклау**

Умартачылык субъектларын аеруча кыйммәтле токымнардан булган бал кортлары белән тәэмин итү, шулай ук аерым территорияләрдә (аларның табигый яшәү ареалларында) аларның токым кыйммәтлелеген яхшырту максатларында кыйммәтле абориген токымнарның генофондын һәм бал кортларының популяцияләрен саклау буенча токым репродукторлары (селекция умарталыклары) һәм республика әһәмиятенә ия дәүләт табигать заказниклары төзелә.

13 статья. **Бал кортлары өчен куркыныч тудыра торган вәзгыятьләр турында умартачылык субъектларына хәбәр итү**

1. Умартачылык субъектларына әйләнә-тирә мохитнең торышы турында, шулай ук бал кортлары өчен куркыныч тудыра торган вәзгыятьләр турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр ителә.

2. Умартачылык субъектлары дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан әйләнә-тирә мохитнең торышы турында, шулай ук бал кортлары өчен куркыныч тудыра торган вәзгыятьләр турында үз вакытында, тулы һәм дөрес мәгълүмат алырга хокуклы.

14 статья. **Умартачылык өлкәсендә ветеринария-санитария контроле һәм хезмәт күрсәтү**

Умартачылык өлкәсендә ветеринария-санитария контроле һәм хезмәт күрсәтү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

15 статья. **Умартачылык өлкәсендәге законнарны бозган өчен җаваплылык**

Умартачылык өлкәсендәге законнарны бозу законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

16 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 22 ноябре
№ 83-ТРЗ